Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
Иске Шөгер авыл җирлеге
Яңа Шөгер авылында гражданнар җыены
КАРАРЫ

2020 елның 20 ноябре № 2

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлегенең Яңа Шөгер авылында 2022 елда үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Иске Шөгер авыл җирлеге Яңа Шөгер авылы гражданнары җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлеге Яңа Шөгер авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, 1 нче төркем инвалидлар, хәрби хәрәкәтләр ветераннары,көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, алар саны җирлек халкының 18 яшькә җиткән гомуми санынннан 30% тан артмый, 300 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:

1) җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял оештыру өчен шартлар тудыру;

- балалар өчен спорт-уен инвентаре сатып алу;

2) җирлек территориясен төзекләндерү буенча башка чаралар:

- МТЗ-82.1 тракторын карап тоту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Лениногорск районы, Яңа Шөгер авылы, Гагарин ур., 1/а адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Иске Шөгер авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Л.М.Шиһапова